ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында” Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында” 1999 елның 17 ноябрендәге 2440 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 1 (1); 2001, № 3; 2002, № 12 (II өлеш); 2004, № 3 (IV өлеш); 2005, № 4 (I өлеш), № 7 – 8; 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3, № 6 (I өлеш); 2013, № 6 (II өлеш), № 11 (II өлеш); 2014, № 7, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

“$2^1$. Җәмәгать судьясы аппараты эшчәнлегенә җитәкчелек итүне тиешле суд участогы җәмәгать судьясы башкара.”;

б) түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

“6. Җәмәгать судьясы аппараты хезмәткәрен башка вазыйфага күчерү, аңа бүләкләү һәм җәза чараларын куллану, шулай ук җәмәгать судьясы аппараты хезмәткәрләренең отпуск графикларын раслау, тиешле суд участогы җәмәгать судьясы белән килештереп, юстиция өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.”;

2) 10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“10 статья. **Җәмәгать судьялары эшчәнлеген оештыру ягыннан тәэмин итү**

1. Җәмәгать судьялары эшчәнлеген оештыру ягыннан тәэмин итү юстиция өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан башкарыла. Җәмәгать судьялары эшчәнлеген оештыру ягыннан тәэмин итү дигәндә гадел хөкемне тулысынча һәм бәйсез гамәлгә ашыру өчен шартлар

тудыруга юнәлдерелгән кадрлар, финанс эше, матди-техник, мәгълүмати һәм башка төрле чаралар аңлашыла.

2. Җәмәгать судьяларына айлык акчалата бүләкләүне, квартал саен акчалата кызыксындыруны, хезмәт өчен түләү фонды акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган башка түләүләрне, федераль законнарда судьялар өчен каралган социаль түләүләрне тәэмин итү, шулай ук торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ җәмәгать судьяларын торак урыннар белән тәэмин итү Россия Федерациясе чыгым йөкләмәсе булып тора һәм Татарстан Республикасында Суд департаменты идарәсе аша башкарыла.

3. Татарстан Республикасы бюджетын үтәү барышында җәмәгать судьялары эшчәнлеген матди-техник тәэмин итү һәм җәмәгать судьялары аппараты хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы нигезендә бюджет классификациясенең тиешле чыгым статьялары буенча тулы күләмдә башкарыла.

4. “Россия Федерациясендә җәмәгать судьялары турында” Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Судьялар советы җәмәгать судьялары эшчәнлеген матди-техник тәэмин итү һәм җәмәгать судьялары аппараты хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү өлешендә Татарстан Республикасы бюджеты проектын эшләгәндә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән үзара эшчәнлек итә. Фикер каршылыклары килеп чыкканда, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Судьялар советы тәкъдимнәрен үзенең бәяләмәсе белән бергә Татарстан Республикасы бюджеты проектына кушымта итеп бирә.

Агымдагы финанс елында җәмәгать судьялары эшчәнлеген матди-техник тәэмин итүгә һәм җәмәгать судьялары аппараты хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүгә бүлеп бирелгән яисә киләсе финанс елына бүленергә тиешле Татарстан Республикасы бюджеты акчалары күләмен 5 проценттан азракка киметү Татарстан Республикасы Судьялар советы ризалыгы белән генә башкарыла ала.

Агымдагы финанс елында җәмәгать судьялары эшчәнлеген матди-техник тәэмин итүгә һәм җәмәгать судьялары аппараты хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүгә бүлеп бирелгән яисә киләсе финанс елына бүленергә тиешле Татарстан Республикасы бюджеты акчалары күләмен 5 проценттан артыгракка киметү Татарстан Республикасы судьялар конференциясе ризалыгы белән генә башкарыла ала.

5. Җәмәгать судьялары тарафыннан гадел хөкем чыгару өчен кирәкле биналар һәм бүлмәләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан бирелә.

6. Җәмәгать судьяларының мәгълүмат ресурсларын берләштерелгән белешмәләр базаларына һәм белешмәләр банкларына кертү чаралары, мәгълүмат системаларының эшләвенә, бердәй принциплар һәм гомуми кагыйдәләр нигезендә эшли торган мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдалануга карата бердәй техник таләпләр урнаштыру Россия Федерациясе Югары Суды каршындагы

Суд департаменты һәм Татарстан Республикасында Суд департаменты идарәсе тарафыннан башкарыла.

7. Җәмәгать судьялары карый торган эшләр буенча федераль бюджет исәбеннән каплана торган чыгымнарны түләү Татарстан Республикасында Суд департаменты идарәсе аша башкарыла.”.

**2 статья**

Әлеге Закон 2018 елның 18 июленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 13 июль
№ 52-ТРЗ